**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552)3-44-22,факс (85552)3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Татар Суыксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставын раслау турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Татар Суыксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставын (алга таба Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Татар Суыксуы урта мәктәбе» МБМУ) яңа редакциядә расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Татар Суыксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорына, мөрәҗәгать итүче булып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Татар Суыксуы урта мәктәбе» Уставын яңа редакциядә теркәгәндә чыгыш ясарга һәм Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче районара салым инспекциясендә гаризаны, башка документларны имзаларга, кирәкле гамәлләрне һәм формальлекләрне башкарырга вәкаләт бирергә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http://aktanysh.tatarstan.ru. үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　И.Ш.Бариев